Чистай муниципаль районы
Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгының
карары

07.03.2019 № 4

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын
үз көчен югалткан дип тану турында

Чистай шәһәр прокурорының 2019 елның 25 февралендәге 02-08-02-2019 номерлы хезмәт күрсәтүнең административ регламентына протестын һәм Чистай шәһәр прокурорының 2019 елның 27 февралендәге 02-08-02-2019 номерлы 2017 елның 16 октябрендәге 17 номерлы карарына протестын карап тикшергәннән соң

КАРАР БИРӘМ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
– Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 16 октябрендәге «Юридик затларга (дәүләт муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга-товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 17 номерлы карарын;
- Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 7 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, физик затларга-товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 14 номерлы карарын.
2. Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, игъланнар стендларында һәм такталарында элеп кую юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://chistopol.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артында калдырам.

Кече Талкыш авыл
җирлеге башлыгы Г.Н.Федотов